# ТАРИХ
## ҺӘМ ҖӘМГЫЯТЬ БЕЛЕМЕ
## ДӘРЕС ЭШКӘРТМӘЛӘРЕ ҖЫЕНТЫГЫ

***«ХӘЗЕРГЕ ВАЗГЫЯТЬ ШАРТЛАРЫНДА МӘКТӘПЛӘРДӘ ТАТАРСТАН ТАРИХЫН УКЫТУ ПРОБЛЕМАЛАРЫ ҺӘМ АЛАРНЫ ХӘЛ ИТҮ ЮЛЛАРЫ» КОНФЕРЕНЦИЯСЕ МАТЕРИАЛЛАРЫ***

# СБОРНИК
## МАТЕРИАЛОВ ПО ИСТОРИИ И ОБЩЕСТВОЗНАНИЮ

***ПО ИТОГАМ КОНФЕРЕНЦИИ НА ТЕМУ: «ПРОБЛЕМЫ ПРЕПОДАВАНИЯ ИСТОРИИ ТАТАРСТАНА В ШКОЛЕ И ПУТИ ИХ РЕШЕНИЯ»***

Редактор: *Сюмбель Таишева*
*Составитель: Инсаф Галяутдинов*
Вёрстка һәм дизайн: *Халитова Эльвина*

6+

Филиал АО «ТАТМЕДИА» редакция журнала «Мәгариф»
420066, г. Казань, ул. Декабристов, 2
www.magarif-uku.ru

Проект журнала «Мәгариф»

# ЭЧТӘЛЕК/СОДЕРЖАНИЕ

**1. Г. ШӘРИПОВА.**
ИЗГЕ БОЛГАР ТАРИХЫН БАРЛЫЙБЫЗ......................................................................**4**
**2. Р. СӨЛӘЙМАНОВ.**
АЛЕКСАНДР II НЕҢ 1861 ЕЛГЫ КРЕСТЬЯН РЕФОРМАСЫ..................................**8**
**4. Р. ХӘЙРУЛЛИН.**
РОССИЯ ҺӘМ ТАТАРСТАН ТАРИХЫНДА ПУГАЧЕВ ВОССТАНИЕСЕ..........**14**
**7. Г. ЗАҺИДУЛЛИНА.**
РУС ДӘҮЛӘТЕ ҺӘМ БАТУ ХАН........................................................................**20**
**8. Л. КОНСТАНТИНОВА.**
МИН – ТАТАРСТАН ГРАЖДАНЫ: ХОКУКЛАРЫМ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫМ..........................................................................................................**24**
**9. А. ГАЗЕТДИНОВА.**
БЕЗ – РОССИЯНЕҢ КИЛӘЧӘГЕ......................................................................**29**
**10. И. ГАЛИМОВ.**
ЯШЬ БУЫННЫ ГРАЖДАНЛЫК ҺӘМ ВАТАНПӘРВӘРЛЕК РУХЫНДА ТӘРБИЯЛӘҮДӘ МӘКТӘП МУЗЕЕНЫҢ РОЛЕ........................................................**32**
11. **Р. ВАФИНА.**
ШКОЛЬНЫЙ МУЗЕЙ КАК ХРАНИТЕЛЬ ИСТОРИЧЕСКОЙ ПАМЯТИ В УСЛОВИЯХ ЦИФРОВОЙ ТРАНСФОРМАЦИИ...........................................................................................**36**
**12. С. ТАРАСОВА.**
СОВРЕМЕННЫЕ ОБРАЗОВАТЕЛЬНЫЕ ТЕХНОЛОГИИ НА УРОКАХ ИСТОРИИ...................................................................................................................**38**
**13. Р. АЗИЗОВА.**
ПАТРИОТИЧЕСКОЕ И КРАЕВЕДЧЕСКОЕ ВОСПИТАНИЕ ШКОЛЬНИКОВ НА УРОКАХ ИСТОРИИ И ВО ВНЕУРОЧНОЕ ВРЕМЯ.......................................................................................................................**40**
**14. Р. ГАРИФУЛЛИН.**
ПРОЕКТНАЯ ДЕЯТЕЛЬНОСТЬ КАК СПОСОБ ФОРМИРОВАНИЯ САМОСТОЯТЕЛЬНОЙ ЛИЧНОСТИ...................................................................................................................**43**

# Изге Болгар тарихын барлыйбыз

*(Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителүгә 1100 ел тулуга багышланган сыйныфтан тыш чара)*



**Гөлшат ШӘРИПОВА,**
*Актаныш районы*
*Пучы урта мәктәбенең*
*тарих һәм җәмгыять*
*белеме укытучысы*

**Максат:** Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителүгә 1100 ел тулу уңаеннан, борынгы бабаларыбызның тарихи-мәдәни мирасына, диненә карата хөрмәт, ихтирам хисләре тәрбияләү.

**Бурычлар:**

*Белем бирүдә:* укучыларны Болгар иленең барлыкка килү тарихы, дине белән таныштыру.

*Үстерелешле:* укучыларны үз фикерләрен дөрес, эзлекле әйтә белергә өйрәтү.

*Тәрбияви:* халкыбызның чал тарихын онытмау, борынгы бабаларыбызның тарихи-мәдәни мирасын өйрәнү аша укучыларда әхлаклылык сыйфатлары тәрбияләү.

**Методлар:** әңгәмә, укытучы сүзе, сорау-җавап, төркемдә эш.

**Җиһазлау:** Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителүгә 1100 ел тулуга багышланган стенд, укучыларның ислам дине буенча язылган рефератлары, стенгазета, ислам дине буенча кроссворд, «Болгар иле» җыры (В. Агапов сүзләре һәм көе).

**Оештыру өлеше:** чарада катнашу өчен бишәр укучыдан торган ике команда төзелә. Жюри сайлана. Команда әгъзаларына бирелгән темага өстәмә чыганаклардан файдаланып әзерләнергә кушыла.

**Сыйныфтан тыш чара барышы**

**Укытучы.** Исәнмесез, балалар! Чарабызны башлап җибәрер алдыннан, бер кроссворд чишеп алыйк әле. Игътибар белән тактага карыйк.

**Горизонталь буенча** *(сулдан уңга)*

1. Ислам динендә югары Илаһи зат. *(Аллаһ)*

2. Ислам диненә нигез салучы зат. *(Мөхәммәд)*

**Вертикаль буенча** *(өстән аска)*

2. Исламның беренче бөек каласы. *(Мәккә шәһәре)*

3. Гарәп кабиләләрен берләштерүгә булышлык иткән дин. *(Ислам)*

4. Мөселман ел исәбе. *(Һиҗри)*

5. Аллаһ йорты. *(Мәчет)*



**Укытучы.** Бик дөрес, булдырдыгыз. Сез ничек уйлыйсыз, бүгенге чарабызда сүз нәрсә хакында барыр икән? Җавапларны нинди тематик төркемгә берләштерергә була?

**Укучылар.** Сүз ислам дине хакында барачак.

**Укытучы.** Әйе, дөрес. Ислам – яшь, чагыштырмача яңа, заманында бөтен дөньяга шактый тиз таралган дин. Соңгы елларда ислам динен белергә омтылыш артканнан-арта бара, бигрәк тә бу дөньяда гына түгел, Татарстан буенча да күзәтелә. Шуңа да республикабызда ислам диненнән азмы-күпме хәбәрдар булмаган кеше юктыр ул. Быелның 21 маенда татарларның борынгы бабалары яшәгән Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителүгә 1100 ел тулуны билгеләп үттек. Тарихи документлар, елъязмалар күрсәтүенчә, Идел буе Болгарстаны исламны 922 елда дәүләтнең рәсми дине буларак кабул итә. Бу елны Болгарга Багдад хәлифәсеннән илчеләр килә һәм Болгар дәүләте исламның төньяктагы форпостына әверелә. Шул уңайдан без дә бүген чарабызны тарихи Болгарыбызда ислам динен кабул итүгә багышладык. Анда катнашу өчен командалар төзелде. 1 нче төркем – «Яшь тарихчылар», 2 нче төркем «Чор тикшеренүчеләре» дип атала.

Чараны «Яшь тарихчылар» төркеме башлап җибәрер. Алар безне Болгарның борынгы чорына сәяхәт итәргә чакыра. *(«Болгар иле» җыры (В. Агапов сүзләре һәм көе) яңгырый.)*

**1 нче укучы.** Болгар җирләренең тарихы бик бай һәм онытылмаслык. Борынгы бабаларыбыз – болгарлар. Заманында Һуннар каганлыгына кергән болгарлар соңрак аннан аерылып чыгып китә, әмма үзләрен һуннарның варислары дип саный. Һун походларында катнашканнан соң, болгарлар Түбән Идел буенда урнаша, анда Идел буе Болгар дәүләтен барлыкка китерәләр. Дәүләт VII йөзнең башында Курбат хан хакимлеге чорында чәчәк ата. Идел Болгарстанының башкаласы Болгар шәһәре X гасырда төзелә.

**2 нче укучы.** Борынгы бабаларыбыз – болгарлар – чыгышлары буенча төркиләр булып, рун язуыннан файдаланган, төрки телдә сөйләшкән. Борынгы болгарлар мәҗүсиләр булган, ягъни күп аллаларга һәм потларга табынганнар, соңыннан бераллалык, ягъни тәңречелек диненә күчәләр.

**3 нче укучы.** Ислам дине Идел Болгарстанына Урта Азия, Якын Көнчыгыш илләре белән үзара сәүдә мөнәсәбәтләре урнашу аркасында үтеп керә. Болгарлар үз дәүләтләрен ныгытырга омтыла, әмма Хәзәр каганлыгына тышкы бәйлелек бу эшне тоткарлый. Икенче сәбәп болгар кабиләләрен берләштерерлек һәм аларны хәзәрләр йогынтысыннан тартып чыгарырлык диннең булмавында, дип фаразлана. X гасыр башларында Алмыш ханның әтисе Багдад хәлифәсенә ислам динен кабул итәр өчен, рәсми илчеләр җибәрүен сорый.

**4 нче укучы.** Болгар иленең рәсми рәвештә ислам динен кабул итүе зур бер тарихи вакыйга була. Ул болгар кабиләләренең берләшеп, бер халык булып оешуына ярдәм итә. Әлеге вакыйганың иң мөһим тарихи дәлиле булып «Ибне Фадланның Идел буена сәяхәте» хезмәте тора. Биредә Изге Болгар җиренә аяк басып, халыкны ислам диненә тартуга булышлык иткән

Багдад илчелеге сәркатибе Ибне Фадлан ясаган чыгыш, аның Идел буе Болгар дәүләтенә кылган сәфәре языла.

**5 нче укучы.** Алмыш патша үзен Алланың җирдәге илчесе дип белдерә. Ислам дине Болгар иленең дәүләт булып ныгуында да сәүдә, һөнәрчелек үсешендә дә әһәмиятле роль уйный. Болгарлар мөселман мәдәнияте белән якынрак таныша, аның бер кисәгенә әйләнә; алар, хәлифәт яклавы астында булу сәбәпле, Хәзәр каганлыгыннан курыкмый башлыйлар. Болгар иле ул чорда дөньяда иң алга киткән ислам илләре белән тыгыз бәйләнешләр урнаштыра. Бу илләрдәге мәдәни, фәнни казанышларның да Болгар дәүләтенә үтеп керүенә җирлек була. Болгар бабаларыбызны иманнары куәтле, ныклы булулары сәбәпле, аларны басып алган мәҗүси монголлар да тиз арада ислам динен кабул итә, һәм Идел буенда бөтен Европага тәэсир итәрлек дәрәҗәсе булган Алтын Урда ислам дәүләте барлыкка килә.

**Укытучы.** Сез үз эшләрегезгә иҗади якын килгәнсез. Темагыз буенча бик күп материал туплагансыз. Рәхмәт сезгә.

Инде сүзне «Чор тикшеренүчеләре» төркеменә бирик.

**1 нче укучы**. Безнең татар ул – борынгы чорда ук үз дәүләтен булдыра алган халык. Тарих күзлегеннән карасак, «Россия территориясендә беренче дәүләтләрне кайсы халыклар оештырган?» дигән сорауга горурланып: «Безнең ата-бабаларыбыз», – дип әйтә алабыз. Татар халкы инде мең елдан артык ислам цивилизациясенең, аның мәдәниятенең аерылгысыз бер өлеше булып тора.

**2 нче укучы.** Бу тарихның, әлбәттә, төрле чорлары булган. Халкыбызны көчләп диннән аеру сәясәтен алып барган патша заманнарында да, меңләгән мәчетләрне җимергән совет атеизмы чорында да ислам дине һәрвакыт халкыбызның рухи таянычы, татарлыкны саклаучы булды. Дингә каршы рәхимсез көрәш алып барган совет чорында ислам Татарстан Республикасы территориясендә, аеруча авыл җирләрендә, гаилә кысаларыннан чыкмады.

**3 нче укучы**. Узган гасырның 90 нчы елларында башланган милли күтәрелеш рухи һәм дини яңарышка юл ачты. Үзгәртеп кору башлану белән, иске мәчетләрне торгызу һәм яңаларын төзү башлана. Татарстанда, татарлар күпләп яшәгән төбәкләрдә йөзләгән мәчет калкып чыкты. Халкыбызның асыл гадәтләре тормышыбызга яңадан кайта башлады.

**4 нче укучы.** Республикабызда мәчет, мәхәлләләр, дингә инанучылар саны көннән-көн арта, ислам дине нигезләрен өйрәнү татарлар арасында көчле бер хәрәкәткә әверелеп бара. 1992 елда төзелгән мөселманнарның Диния нәзарәте Россия Федерациясе мөфтиятләре арасында иң зурысы санала һәм бу изге эштә таяныч булып тора. Нәзарәт татарның үз дини мирасын кайтаруга зур игътибар итә. Аның башлангычында Болгар тарихи-архитектура тыюлыгында мөселманнарның «Изге Болгар җыеннары» уздырыла.

**5 нче укучы**. Болгар истәлекләрен тергезү, төзекләндерү һәм аларны халыкларга күрсәтү өчен Татарстанда «Болгар» фонды булдырыла. Шуның булышлыгында

Болгарда зур комплекс барлыкка килде. Фондта 100 меңгә якын экспонат саклана. Болгар бабаларыбызның ислам динен кабул итү көнен искә алу йөзеннән 1989 елдан башлап ел саен ун меңләгән кеше бирегә килеп, хаҗ кыла. Биләр шәһәрчеге дә республиканың тарихи-архитектура тыюлыгының «Көмеш божра»сына керә һәм «Хуҗалар тавы» итәгенә урнашкан изге чишмәгә барып гыйбадәт кылу кебек мөселманнарның мөһим гореф-гадәте үз асылына кайтты.

**Укытучы.** Рәхмәт. Сезнең төркем дә тема буенча күп материал туплаган, шуңа җавабыгыз да тулы. Булдырдыгыз, афәрин.

Ә хәзер бераз белемнәрегезне тикшереп алу өчен «Сораулар һөҗүме» уенына күчик. *(Болгар иле, аның дине турындагы сорауларны бер-бер артлы биреп, бер төркем икенчесенә «һөҗүм» итә. Командалар сорау бирү тәртибен ачыклау өчен жирәбә сала.)*

Беренче булып, **«Яшь тарихчылар» төркеме** сорау бирә:

1. Болгар дәүләтенең нинди шәһәрләре булган? *(Болгар, Бүләр, Богдашкино, Җүкәтау, Суар, Әҗмер, Кашан, Ашлы , Тубылгытау, Алабуга, Борынгы Чаллы шәһәрлекләре билгеле.)*

2. Болгарның кайсы төбәкләрендә беренче мөселман җәмәгатьләре барлыкка килә? Мөселманлашуның якынча тәмамлану вакытын әйтегез. *(Башта мөселман җәмәгатьләре Болгар, Суар, Биләрдә барлыкка килә. X йөз ахырына илнең барлык халкы диярлек мөселманлаша.)*

3. X йөз – XI йөзнең беренче утыз елында хакимлек иткән Болгар идарәчеләренең титуллары нинди булган? *(Алар X йөз башында – илтәбәр, X йөз уртасыннан әмир титулы йөртә.)*

4. Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине таралу ничәнче гасырга туры килә? *(X гасыр)*

**Укытучы**. Афәрин. Ә хәзер **«Чор тикшеренүчеләре»** үз сорауларын бирәчәк.

1. X йөз – XI йөзнең беренче утыз елында хакимлек иткән Болгар идарәчеләреннән кемнәрне беләсез? *(X йөз – XI йөзнең беренче утыз елында хакимлек иткән Болгар идарәчеләреннән Шилки, Алмас (Алмыш), Микаил бине Җәгъфәр, Микаил бине Әхмәд, Абдуллаһ бине Микаил, Талиб бине Әхмәд, Мөэмин бине Әхмәд, Мөэмин бине Хәсән, Абдрахман бине Мөэмин, Әбү Исхак Ибраһим бине Мөхәммәд исемнәре билгеле.)*

2. Изге Болгар территориясендә ислам динен тарату башлангычы кем исеме белән бәйле? *(Гарәп сәяхәтчесе Әхмәд ибне Фадлан белән бәйле.)*

3. Идел буе Болгарында иң борынгы дин формасы нинди булган? *(Башлангыч чорда төркиләр күпаллалыкка нигезләнгән мәҗүсилеккә табына, соңыннан бераллалык, ягъни тәңречелек диненә күчәләр.)*

4. Идел буе Болгары чорында яшәгән Кол Галинең кайсы әсәрендә пәйгамбәр образы яктыртыла? *(Кол Гали үзенең «Кыйссаи Йосыф» поэмасында Йосыф пәйгамбәр образын гәүдәләндерә.)*

**Укытучы.** Афәрин, булдырдыгыз. Җиңүчеләрне билгеләү өчен, хөкемдарларга сүз бирәбез. *(Хөкемдарлар, тупланган очколарны санап, җиңүче команданы игълан итә. Бүләкләр тапшырыла.)*

**Укытучы.** Укучылар, бүгенге сөйләшүләрдән сез үзегезгә файдалы һәм кызыклы мәгълүмат

туплый алгансыздыр, дип уйлыйм. Борынгы бабаларыбыз ислам динен иң югары дәрәҗәдә акыл һәм белем, әхлак, тынычлык һәм камиллек дине буларак сайлап алган һәм бер дә ялгышмаганнар. Ислам диненең Идел буе төбәкләрендә инде 1100 ел дәвамында яшәп килүе – моңа чын дәлил. Ислам дине, фәлсәфи, идеологик, хокукый һәм әхлакый дин буларак, архивыбызда зур урын алып тора һәм халкыбыз тормышында әһәмиятле рухи корал хезмәтен үти.

Бүгенге чарабыз шуның белән тәмам. Сау булыгыз!

**Кулланылган әдәбият**

*Абдуллин Я.А*. Ислам халкыбызның яшәешендә. Ислам в истории и культуре татарского народа. – Казань, 2000.

*Арсланова Ф.* Ислам – әхлак, тынычлык дине //Мәгариф. – 2003. – № 12.

*Дәүләтшин Г.* Болгарда ислам // Мирас.–1994. – №5 – 6.

Ислам. Белешмә-сүзлек. – Казан: Татар. кит. нәшр.,1993.

Краткая история ислама: учебное пособие. – Казань: Дом печати, 1997.

*Марданшин М.М*. История ислама. – Казань: Яз, 2012.

Религия мира и добра: школьникам о исламе: Пособие для факультатив. занятий / Л.А.Харисова. – Казань: Магариф, 1999.

*Саматов Г.* Милләтебездә ислам дине. – Казан: Иман,1998.

*Хәбибуллин М*. Ханнар тарихы // Мирас. – 1992. – № 6.

*Фәхреддин Р.* Ибне Фазланның тәрҗемәи хәле вә сәяхәтнамәсе // Болгар вә Казан төрекләре. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1993.

*Фәхретдинов Р.* Бөек Болгар иле // Мирас.–1997.–№12.

# Александр II нең 1861 елгы крестьян реформасы



**Рамил СӨЛӘЙМАНОВ,**
*Аксубай районы*
*Иске Ибрай урта мәктәбенең*
*тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы*

**Дәрес тибы:** яңа белемнәрне ачу дәресе.

**Дәрес максатлары:**

**Эчтәлек ягыннан***:* Россиядә һәм Казан губернасында крепостной крестьяннарны азат итү реформасы тарихын, реформа барышын, сәбәпләре, эчтәлеге һәм нәтиҗәләрен өйрәнү; илдә икътисад үсешен тоткарлаган феодаль тәртипләрне бетерү кирәклеге асылын һәм гражданлык хокукларын тормышка ашыру өчен Александр II «Манифесты», реформалар башлангычы икәнен аңлау.

**Эшчәнлек ягыннан:** анализлый, гомумиләштерә, нәтиҗәләр ясый, документлар, таблицалар, дәреслек белән эшли белү күнекмәләре булдыру;

1861 елның 19 февралендә «Крепостной бәйлелектән азат ителгән крестьяннар турында гомуми нигезләмә», «вакытлыча бурычлы», «кисенте», «йолым», «халык арадашчысы», «Бизднә кыйнашы» терминнарын әйләнешкә кертү; үз белемнәрен бәяләргә өйрәтү.

**Дәрес методлары:** өлешчә эзләнү, интерактив технология, проект, критик фикерләү технологиясе, мәгънәви уку стратегиясен кабул итү.

**Эшне оештыру төрләре:** индивидуаль, парларда, төркемнәрдә, күмәк.

**Җиһазлау:** дәреслекләр:

1. Россия тарихы. 9 сыйныф. А.В.Торкунова редакциясендә. – М.: Просвещение, 2020.
2. Галлямова А. Г., Загидуллин И.К. Фахрутдинов Р.Р. Татарстан и народы Татарстана. XIX – начало XX вв.– Казань, 2019. – 96 с.
3. Документ «Манифест о всемилостивейшем даровании крепостным людям прав состояния свободных сельских обывателей».
4. Документ «Общее положение о крестьянах, вышедших из крепостной зависимости».
5. Проектор, ноутбок, экран, презентация, бәяләү карточкасы.

**Предметара бәйләнеш:** тарих, җәмгыять белеме, Татарстан тарихы, туган якны өйрәнү, литература.

**Дәрес барышы**

**I. Уку эшчәнлегенә мотивация булдыру**

**Укытучы.** Хәерле көн, укучылар! Сезне күрүемә бик шатмын һәм дәрестә нәтиҗәле эшләрбез дип уйлыйм.

Бер кул белән кул чабып буламы? Әлбәттә, юк! Тавыш чыксын өчен, икенче кул кирәк. Кул тавышы ул – ике кул эшчәнлеге нәтиҗәсе. Укытучы нинди генә оста булмасын, ул – бер кул, икенче кулдан (сез) башка, без ялгыз. Бергә күмәк эшләгәндә генә, теләсә нинди авырлыкларны җиңәрбез. Дәресебез нәтиҗәле үтсен өчен, әйдәгез, кул чабып бергә эшкә керешик.

Сезнең алда «Белемнәрне бәяләү» карточкалары ята. Дәрес барышында тутыра барырга да онытмыйбыз.

Игътибар экранга!

Бирелгән саннарны гомуми нинди вакыйгалар бәйли?

1) 1497, 1550, 1581, 1597, 1649 –
2) 1797,1804, 1842 –

Димәк, беренче рәт – крестьяннарны крепостнойга әйләндерү вакытлары (1497 – Иван III Хөкем китабы, 1550 – Иван IV Хөкем китабы, 1581 – тыелган еллар указы, 1597 – качкын крестьяннарны эзләүнең 5 еллык вакытын билгеләү, 1649 – Собор Уложениесе) , икенчесе – Павел I (барщинаны 3 көнгә калдыру указы), Александр I («Ирекле иген игүчеләр» указы), Николай I («Йөкләмәле крестьяннар турында» указ).

**Укытучы.** Ә менә барлык бирелгән даталар һәм кабул ителгән указларны нинди эш-гамәл (процесс) берләштерә?

**Укучылар.** Крепостной хокукны урнаштыру һәм крестьяннарны азат итәргә омтылу.

**Укытучы**. Рус дәүләтендә крепостной хокукның гасырлар буена яшәве вакытына игътибар итегез!

**II. Белемнәрне актуальләштерү һәм сынау уку гамәле**

**Укытучы**. Өй эше материалларына таянып, крепостной хокукның бетерү кирәклеге

алшартларын ачыклагыз? (§17)

**Укучы** (телдән).

1. Крепостной хокук илнең үсешен тоткарлавын җәмгыять әгъзаларының аңлавы.
2. Европа илләреннән үсеш дәрәҗәсе буенча артка калу.
3. Алпавыт хуҗалыкларының кереме – аз, яңалыклар кертүгә омтылмау.
4. Натураль хуҗалык алып бару, илнең эчке сәүдә үсешен тоткарлый.
5. Җитештерүче хуҗалыклар өчен ирекле эшче куллар җитешмәү.
6. Крестьян чыгышларының көчәюе һәм башка җаваплар.

**1 нче бирем.** Бирелгән вариантлардан сәбәп-тикшерү мөнәсәбәтләрен торгызыгыз! (Причинно-следственные связи) (экранга чыгарыла)

А) Авыл хуҗалыгында капиталистик мөнәсәбәтләр аз үсеш алган.

Б) Ялланган хезмәт үсеш ала алмый.

В) Крепостной хокук.

Г) Промышленность үсешен тоткарлый.

Җавап: В – А – Б – Г.

**2 нче бирем.**

А) Кырым сугышында җиңелү.

Б) Икътисади-техник үсеш яктан артка калу.

В) Бөек держава статусын югалтудан курку.

Г) Крепостной хокук.

Д) Крепостной хокукны бетерү.

Җавап: Г – Б – А – В – Д.

**Укытучы.** Дәфтәрләрне уң як күршегез белән алышыгыз, тикшерегез һәм билгеләр куегыз! Билгеләрне бәяләү карточкасына төшерергә онытмагыз! (*Җаваплар экранга чыгарыла.)*

**III. Авырлыкларның урынын һәм сәбәпләрен ачыклау**

**Укытучы.** Кайсы биремнәрне эшли алмадыгыз? Төркем белән аралашып яки дәреслек материалыннан дөрес җавапларны табыгыз. «А» төркеме (көчле укучылар) «В» төркеменә (йомшак укучылар) булышабыз.

**IV. Уку эшчәнлегендә авырлыктан чыгып проектлар төзү**

**Укытучы.** XIX гасыр уртасында Россиядә буржуаз реформалар өчен алшартлар туа. Ничек уйлыйсыз? Бүгенге дәресебезнең темасын билгеләгез?

**Укучы.** Дәресебез темасы: «Крепостной хокукны бетерү» *(дәфтәргә язалар).*

**Укытучы.** Яңа темабызның максатларын билгелибез?

**Укучы.** Крепостной хокукны бетерү тарихын өйрәнәбез. Реформаның эчтәлеген һәм нәтиҗәләрен өйрәнәбез?

**Укытучы.** Дәреснең төп проблемалы биреме: халык Александр II гә «Азат итүче патша» кушаматы бирә. Дәрес ахырында без килешергә яисә кире кагарга тиеш булабыз.

**Дәрес планы**

1. Яңа император.
2. Крепостной хокукны бетерү сәбәпләре.
3. Реформаны әзерләү һәм эчтәлеге.
4. Казан губернасында реформа барышы.
5. Реформаның әһәмияте.

**V. Төзелгән проектны тормышка ашыру**

**Укытучы.** Беренче план пункты буенча дәреслекнең 117 нче битеннән Александр II биографиясе белән танышабыз һәм түбәндәге сорауларга җаваплар эзлибез:



Сергей Левицкий фотосы

1) Кем улы?
2) Ничәнче елда тәхеткә утыра?
3) Тәхеткә әзерлеге һәм карашларын ачыклыйбыз?
4) Реформалар үткәрергә нинди вакыйгалар этәрә?

**Укытучы**. Крепостной хокукны бетерү сәбәпләре белән танышып чыгыгыз һәм тезислар формасында дәфтәргә теркәгез.

**Укучы.**

- Индустриаль илләрдән артка калуын юкка чыгару зарурлыгы;
- Ирекле эшче куллар булмавы икътисад үсешен тоткарлый;
- Социаль киеренкелекне киметү зарурлыгы;
- Феодализмның саклануы заман таләпләренә җавап бирмәү.

**Укытучы.** Дворяннарның өчтән ике өлеше реформа үткәрелүенә каршы. Мондый шартларда хакимиятнең реформаны үткәрү эшчәнлеге белән танышып, реформа үткәрү өчен комиссияләр төзелү таблицасын тутырыгыз!

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| Яшерен комитет (1857) | Губерна комитетлары (1857–1858) | Баш комитет (1858) | Редакция комиссиясе (1859) | Дәүләт советы (1860–1861) |

1857 елда Крестьян реформасы проектлары өйрәнү өчен Яшерен комитет оештырыла. 1858 елда алпавытлардан торган губерна комитетлары реформа проектлары эшләп тапшыралар. Баш комитет крестьяннарны азат итү мәсьәләләрен хәл итә. Редакцион комиссия – проектларны тикшереп, ил өчен бердәй закон әзерли. Комиссия җитәкчесе – Дәүләт Советы әгъзасы Я. И. Ростовцев.

1861 елның 19 февралендә император Александр II «Крепостной бәйлелектән азат ителгән крестьяннар турында гомуми нигезләмә»гә кул куя.

**Укытучы.** Әлеге датага игътибар итегез һәм истә калдырабыз.

Сезнең алда һәм экранда «1861 ел Манифесты». Документны анализлап, түбәндәге сорауларга җавап бирегез:

А) Әлеге реформа нинди төркем крестьяннарга кагыла?

Б) Крестьяннар нинди хокуклар алалар?

В) Реформадан соң җир кем милке булып кала?

Г) Нинди шартларда крестьяннар җир хуҗасына әвереләләр?

**Таблица белән эш.** Укытучы сөйләгән һәм документ белән эш вакытында тутырыла.

| **Реформага кадәр крестьяннар хәле** | **Реформадан соң** |
|---|---|
| 1. Шәхси бәйлелек | 1. Шәхси ирекләр, гражданлык хокуклары |
| 2. Җир алпавытлар кулында | 2. Җир белән азат ителә. Артык җирләрне кисеп алалар (кисентеләр), аз булса өстиләр яки йолым акчасын киметәләр |
| 3. Барщина, оброк | 3. Вакытлыча бурычлылар: барщина, оброк |

| | |
|---|---|
| 4. Алпавыт хөкеме һәм идарәсе | 4. Җир өчен йолым акчалары: 20 % – крестьян, 80 % – дәүләт (ел саен җир бәясенең 6 % ын түләп барып, 49 ел эчендә түләп бетерергә) |
| | 5. Крестьяннарның хәле алпавыт белән җәмәгать арадашчылары катнашында алыш-биреш шартлары күрсәтелгән устав грамотасы белән билгеләнә |
| | 6. Авыл, волость җыены идарәсе хакимлегенә әләгә |

**Укытучы.** Дәреслегебезнең 122 нче битен ачабыз һәм карта белән эшлибез.

Карта ярдәмендә 1861 елгы реформа нәтиҗәсендә кайсы территорияләрдә җирләрнең киселүен, ә кайсыларына өстәп бирелүен ачыклагыз?

Казан губернасы нинди зонага керә?

**Укучы.** Җирләре 20–40 % ка кадәр киметелгән губерналар исемлегенә кертелгән.

*Физкультминут*

**VI. Тышкы сөйләмдә беренчел ныгыту**

**Укытучы.** Казан губернасында Крестьяннарны азат итү манифесты 1861 елның 11 мартында игълан ителә. Реформа нәтиҗәсендә алпавыт җирләре 11,6 % ка, ә крестьяннарныкы 23,6 % ка кими. Вакытлыча бәйле крестьяннар барщина яисә оброк түләргә тиеш булалар. Имана өчен оброк күләме 8–9 сум. Барщина күләме: бер елда ирләр үз инвентаре белән
40 көн, хатын-кызлар 30 көн эшләргә тиешләр.

Йолым түләүләре авыр йөккә әверелә. Губернада алпавыт крестьяннары өчен имана җиренең бер дисәтинәсе 22 сумнан күбрәк торган. Бирелгән җирләре өчен крестьяннар 3,4 миллион сум урынына ике тапкыр артык түләгәннәр.

Укучылар! Ничек уйлыйсыз? Крестьяннар реформа шартлары белән ризалармы?

**Укучы.** Юк! Алпавыт белән мөнәсәбәтләрне кичекмәстән туктату һәм бушлай җир алу – тормышка ашмый. *(Фикерләр алышу.)*

**Укытучы.** Ә хәзер «Татарстан һәм татар халкы» дәреслегенең 207 нче битеннән «Крестьян чуалышлары. Куртина чиркәвендәге панихида» өлешеннән Спас өязенең Рус Бизнәсе авылы вакыйгалары белән танышып чыгабыз. Түбәндәге сорауларга җаваплар бирегез:

А) Бизнә вакыйгаларына үз билгеләмәгезне тәкъдим итегез һәм нигезләгез?

Б) Крестьяннар реформаның нинди шартлары белән риза булмаганнар?

**Укытучы.** 1863 елда крестьян реформасының төп положениелә-
ре – удел крестьяннарына, 1866 елда дәүләт крестьяннарына үткәрелә. Без сезнең белән яшәгән Аксубай районы Иске Ибрай авылы крестьяннары
– ул чорда дәүләт крестьяннары категориясенә кергәнбез. Чагыштыру өчен бер генә мисал китерәм. Дәүләт крестьяннары җан башына уртача: руслар – 6,4 дисәтинә, мордва һәм удмурд-
лар – 6 шар, марилар – 5,7 шәр, чувашлар – 5 әр, татарлар 4,7 шәр җир алганнар. Әлеге саннардан үзегез нәтиҗә ясагыз.

**VII. Мөстәкыйль эш һәм эталон буенча тикшерү**

**Укытучы.** Дәфтәргә язма эшлибез!

1. *Түбәндәге терминнарга аңлатма бир:*

Крепостной –

Вакытлыча бурычлы –

Йолым түләү –

2. Устав грамоталарын раслау һәм крестьяннар һәм йорт хуҗалары арасындагы бәхәсләрне хәл итү өчен

билгеләнгән вазифаи зат.

А) Судья; Б) депутат;
В) староста; Г) помещик;
Д) халык арадашчысы

3. Помещикның крестьяннар белән килешүе сатып алу операциясенең күләме һәм шартлары турында

А) договор; Б) устав грамотасы; В) килешү

**VIII. Белем системасына кертү һәм кабатлау этабы**

**Укытучы.**

— Бүгенге дәреснең темасын әйтегез?

— Дәрестә нинди максат куйдык? Аңа ирештекме?

— Авыл хуҗалыгында нинди үзгәрешләр булды?

— Реформа елларын әйтегез?

— Н.А.Некрасовның әлеге шигырь юлларына һәм рәсемгә үз фикерләрегезне әйтегез?

«Распалась цепь великая,
Распалась и ударила,
Одним концом – по барину,
Другим – по мужику».



*Ярлы крестьян үзенең җирендә. «Новый сатирикон» журналыннан рәсем, 1917 ел*

**Укытучы.** Дәреснең төп проблемалы биреме: халык Александр II гә «Азат итүче патша» кушаматы бирә. Дәрес ахырында без килешергә яисә кире кагарга тиеш булабыз дип сөйләштек. Ничек уйлыйсыз? Әлеге кушамат чынбарлыкка туры килдеме? Җавапларыгызны дәлилләгез?

(*Укучыларның фикерләре тыңлана.)*

**Укытучы.** Димәк, дәресебез темасына нәтиҗә ясап, 1861 елгы реформа илдә 24 миллион крестьянга шәхси ирекләр бирә. Җир крестьяннар теләгәнчә шәхси милек итеп бирелми. Крестьяннар 49 ел буена вакытлыча бурычлы булып калалар. Җирне сатып алырга, арендага бирергә, мирас буенча тапшырырга рөхсәт ителә. Реформа өстән дәүләт тарафыннан үткәрелә. Алпавытлар, дәүләт, крестьяннар мәнфәгатьләрен исәпкә алып үткәрелә.

Киләсе дәресебездә гражданлык хокукларын тормышка ашыручы реформалар барышын өйрәнербез.

**IX. Рефлексия**

Өй эше:

1) **Мәҗбүри бирем:** *§ 18, 1–8 сорауларга телдән җаваплар әзерләргә.*

2) **Ярым иҗади бирем:** бирелгән акчалар турында мәгълүмат тап.




**Укытучы.** Ә хәзер дәрестә эшегезне бәяләп, билгеләр куеп, «бәяләү карточкасы»н миңа тапшырыгыз?

(*Укучылар «Бәяләү карточкасын» тутырып, укытучыга тапшыралар)*

**Укытучы.** Ә хәзер телдән дәресебезне бәяләгез?

— Мин нәрсә белми идем...

— Дәрес материалы мине уйларга этәрде...

— Мин нәрсәгә өйрәндем...

— Тәкъдимнәр...

Укучылар, бүгенге дәресебез тәмам. Киләчәктә сезгә уңышлар. Сау булыгыз!

# Россия һәм Татарстан тарихында Пугачёв восстаниесе

*(8 нче сыйныфта тарих дәресе)*



**Ринат ХӘЙРУЛЛИН,**
*Мамадыш районы Урта Кирмән урта мәктәбенең тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы, Р. Фәхреддин исемендәге республика премиясе лауреаты*

**Дәрес тибы**: яңа материал өйрәнү.

**Максат:** укучыларны 1773–1775 еллардагы крестьяннар сугышының сәбәпләре, максатлары, хәрәкәтләндерүче көчләре, төп этаплары һәм вакыйгалары, нәтиҗәләре белән таныштыру, Емельян Пугачёв шәхесенә характеристика бирү.

**Бурычлар:**

*Белем бирүдә:*

– тема буенча тарихи белемнәр үзләштерү, шулай ук Е.Пугачёв күтәрелешенең үзенчәлекләрен өйрәнү;

– указ текстлары белән танышу аша темага кагылышлы төп төшенчәләрне өйрәнү, хәтергә алу;

– күтәрелешнең безнең төбәктәге чагылышы, анда татарларның катнашуы белән танышу.

*Үстерелешле:*

– укучыларның телдән җавап бирү аша тарихи белемнәрне куллана алу сәләтләрен, танып белү активлыгын үстерү;

– Е. Пугачёв җитәкчелегендәге күтәрелеш турындагы төрле чыганаклардагы мәгълүматны табу, анализлау, чагыштыру, бәяләү күнекмәләрен үстерү;

– укучыларның фикерләү эшчәнлеген үстерү: синквейн төзү эше аша чагыштыру, анализлау, гомумиләштерү, нәтиҗә ясау күнекмәләрен үстерү;

– таблицаны тутыру буенча фикер алышу аша укытучы һәм башка укучылар белән күмәк эшчәнлек һәм хезмәттәшлеккә ирешү сәләтләрен үстерү.

*Тәрбияви:*

– XVIII гасырдагы халыкның төрле социаль катлауларының җәмгыятьтәге урыннары белән танышу аша укучы шәхесенең гражданлык үзбилгеләнү нигезләрен формалаштыру;

– телдән ясалган чыгышлар аша аралашу культурасы тәрбияләү;

– парлап эшләү аша укучыларда үзара ярдәмләшү, иптәшлек хисләре тәрбияләү;

– эш дәфтәрләрендә эшләү аша укучыларда мөстәкыйльлек хисләре тәрбияләү.

**Методлар:** телдән (әңгәмә, хикәяләү), күргәзмә, гамәли методлар (гамәли мисаллар эшләү), проблемалы-эзләнүле (чыганаклардан мәгълүматлар эзләү), белем алуга омтылышны стимуллаштыру методы, укучыларның мөстәкыйль эшчәнлеге методы.

**Оештыру формалары:** фронталь эш, парлап эшләү, индивидуаль эш.

**Төп төшенчәләр:** «Кызыктыру грамоталары» – күтәрелешкә, бунтка чакыру өндәмәләре.

**Төп даталар:** 1773–1775 еллар – Е.Пугачёв җитәкчелегендәге күтәрелеш. 1774 елның 4 июле – Е.Пугачёвның Вятканы кичеп, Мамадышка килүе. 1775 елның 10 гыйнвары – Е.Пугачёвны җәзалау.

**Җиһазлау:** проектор, монитор, эш дәфтәре, дәреслекләр (Арсеньев Н.М., Данилов А.А. История России. 8 класс. В 2-х частей. – М.: Просвещение, 2018.; Пискарёв В.И. История Татарстана и татарского народа. 18 век. – Казань: ТКИ, 2018), атлас, карточкалар.

XVIII гасырда Россиядә драматик төсмер алган һәм тетрәндергеч вакыйгаларның берсе – Е.Пугачёв җитәкчелегендәге восстание. Анда Россиянең төрле катлам кешеләре, Идел-Урал халкы, шул исәптән татарлар да катнашкан. Алай гына да түгел, әлеге күтәрелеш безнең Мамадыш өязен дә чолгап ала, авылыбыз крестьяннары да анда актив катнаша. 1774 елның җәендә Пугачёв, Каманы үтеп чыгып, Алабуга, Минзәлә, Зәйне ала, 4 июльдә Вятканы кичеп, Мамадышны ала. 6 июльдә Казанга юл тота. 11 июльдә Казанга килеп җитә һәм Арча кырыннан ерак түгел генә лагерен урнаштыра. Шәһәр халкы арасында ыгы-зыгы башлана. Шәһәр хакимияте Казанны ныгытуга зур көч куя. Шәһәрне һәм аның оборонасын ныгыту планына Екатерина II үзе күрсәтмә бирә. Бу план буенча, Арча кыры ягыннан Казансу елгасы буйларына өстәмә фортификацион ныгытмалар булдырыла. Казан гарнизонында 2 меңнән артык кеше исәпләнелә. Шәһәрне саклау П.Потёмкинга йөкләнә. Пугачёв армиясе якынча 20 мең кешедән торган, ләкин аларның күпчелеге начар әзерлекле һәм коралланмаган була. Казан алына. Хөкүмәтнең калган гаскәре Кремльгә кереп бикләнә. Эре губерна шәһәре булган Казанның алынуы Россия җәмәгатьчелегендә көчле резонанс тудыра. Тарихчылар фикеренчә, Казанның алынуы восстаниенең иң биек ноктасы була.

Татарстан, безнең төбәк тарихында тирән эз калдырган бу вакыйгаларны 8 нче сыйныфта интеграль дәрес итеп уздыру отышлы һәм үзен аклый, дип саныйм.

**Дәрес барышы**

**I. Мотивацион-максат кую этабы**

*Әлеге этапта укытучы эшчәнлеге.* Сәламләү. Укучыларны кызыклы эшкә әзерләү. «Фетнәле гасыр», XVII гасырда Россиядә фетнәләр һәм күтәрелешләр буенча узган материалны искә төшерү.

А.С.Пушкинның «Капитан кызы» романының төп герое Пётр Гринёвның: «Мәгънәсез һәм рәхимсез рус фетнәләрен күрергә насыйп итмә, Ходаем!» – дигән сүзләре буенча фикер алышу. Дәреснең темасын һәм максатын билгеләү.

*Укучылар эшчәнлеге:*

**танып белүдә:** укучылар «Фетнәле гасыр», Пётр Гринёвның искә алынган әйтемнәре буенча фикер алышуда катнашалар, дәреснең темасын һәм максатын билгелиләр, эш дәфтәрләренә язып куялар. Әлеге эшчәнлек нәтиҗәсендә эшкә кереп китү сәләтләре үсә. Укытучы тарафыннан махсус булдырылган ситуациядә билгелене билгесездән аерырга

өйрәнәләр. Мәгълүматны анализлау, нәтиҗә ясау осталыклары үстерелә;

**регулятив эшчәнлек:** укытучы белән берлектә дәреснең темасын һәм максатын формалаштыралар. Үз-үзләрен эшкә туплый алу, үзләренең җавапларын корректлау сәләтләре үстерелә;

**коммуникатив эшчәнлек:** телдән сөйләгәндә, фикерләрен формалаштыралар, үз фикерләрен тарихи фактлар белән раслыйлар.

**II. Ориентлашу этабы**

*Укытучы эшчәнлеге:* укучылардан дәреснең бурычларын билгеләүне үтенә. Бурычларны ачыклаганнан соң, укучылар белән бергәләп эшчәнлекнең алдагы планын булдыра.

*Укучылар эшчәнлеге:*

**танып белүдә:** Пугачёв күтәрелеше белән танышырга мөмкинлек бирәчәк сораулар белән танышу. Алга таба эшчәнлекне планлаштыралар.

Мәгълүматны анализлый белү, сорауларны төзү һәм кую осталыклары үсә. Тәкъдим ителгән бурычлар планын анализлау, төзәтмәләр кертү сәләте арта;

**регулятив эшчәнлек:** укытучы белән булган диалог аша башкарган эшләренең уңышлылык дәрәҗәсен билгелиләр.

Куелган бурычлардан чыгып, үз эшләрен планлаштыру сәләтләре үсә;

**коммуникатив эшчәнлек:** Монологик һәм диалогик сөйләм алымнарын куллану аша башкаларга үз позицияләрен җиткерәләр.

Укучыларның әңгәмәдәшкә аңлаешлы фикерләр формалаштыру осталыгы, үз фикерләрен телдән әйтә белү; башкаларның сөйләмен тыңлый һәм аңлый белү осталыгы, үзенең гипотезаларын булдыру, аларны нигезли белү осталыклары арта.

**III. Эзләнү-тикшеренү этабы**

*Укытучы эшчәнлеге:* Екатерина II вакытында төп социаль катлауларның социаль көнкүреше турында чыгыш ясаган укучының чыгышы буенча фикер алышырга тәкъдим итә.

**Фронталь сораштыру.** Крестьяннар нидән канәгать булмыйлар? Эшле кешеләр нидән канәгать булмыйлар? Казаклар, рус булмаган халыклар нидән канәгать булмыйлар?

Укучыларга җаваплар язарга тәкъдим итә. **(1 нче бирем)** Укучыларның үз эшләрен бәяләүләрен сорый.

Емельян Пугачёвның кыскача биографиясе белән таныштыра. Шуның нигезендә укучыларга эш дәфтәрләренә Пугачёв турында синквейн төзергә куша. **(2 нче бирем)** Төзелгән синквейннар буенча фикер алышу оештыра. Пугачёв тарафыннан халыкка җибәрелгән «Кызыктыру грамоталары» белән танышырга куша. **(3 нче бирем)** Тексттан Пугачёвның халыкка игълан итәргә теләгән указ һәм манифестларын табарга куша. *(Казанда 1925 елда басылган «Причал» журналының 5 нче санындагы язма кулланыла, 16 нчы бит.)* Башкарылган эшнең нәтиҗәләре буенча фикер алышуны оештыра, Пугачёвның ялган үзбилгеләнгән (самозванец) булуына басым ясала.

*Укучылар эшчәнлеге:*

**танып белүдә:** сыйныфташларының сөйләмен тыңлыйлар. Фикер алышуда катнашалар. Эш дәфтәрләренә һәр социаль катлауның нидән канәгать булмауларын язалар. Пугачёвның биографиясен тыңлыйлар, шул мәгълүмат нигезендә 2 нче биремне башкаралар. Эш нәтиҗәләре буенча фикер алышуда катнашалар. Пугачёвның указ һәм

манифестларыннан фрагментлар укыйлар, авторның кешеләр тормышын ничек үзгәртергә теләве, ниләр вәгъдә итүе белән танышалар. Пугачёв программасы буенча укытучы биргән сорауларга җавап бирәләр.

Мәгълүматны кабул итә, фактларны анализлый, нәтиҗәләр ясый белү осталыклары, биш җөмлә белән кыскача, тәмамланган хәбәр төзү сәләтләре үсә;

**регулятив эшчәнлек:** фикер агышын, мантыйклы аңга алуны контрольдә тоталар. Эш дәфтәрләрендәге эшләрен бәялиләр. Укытучы белән әңгәмәдә эшләнгән биремнәренең уңышлылык дәрәҗәсен билгелиләр. Җибәрелгән хаталарының сәбәбен, төзәтү юлларын табалар. Эш дәфтәрендә башкарылган эшкә үзбәя бирәләр.

Логик фикерләрен корректировкалау сәләтләре, биремнәрне аңлый һәм кабул итү осталыклары, үзләренең эш-гамәлләрен контрольдә тоту осталыклары үстерелә;

**коммуникатив эшчәнлек:** үз фикерләрен әйтәләр һәм башкаларны тыңлыйлар, ситуациягә үз карашларын белдерәләр, аны аргументлар кулланып яклыйлар. Партадашлар белән текст буенча фикер алышалар. Үз фикерләрен җиткерәләр. Иптәшләрен тыңлыйлар, фикерне тулыландыралар.

Үз фикерләрен телдән әйтә белү; башкаларның сөйләмен тыңлый һәм аңлый белү осталыгы үсә. Диалогик һәм монологик сөйләм күнекмәләре үсә. Башкалар фикерен тыңлый белү, корректлы итеп тулыландыру һәм хаталарны төзәтү осталыгы үсә.

**Ял минуты**

*Укытучы эшчәнлеге:* укучыларга дәреслекнең 27–28 нче битләрендәге күтәрелешнең төп вакыйгалары турындагы материал белән мөстәкыйль танышырга куша. Текст белән танышу барышында эш дәфтәрләрендә 4 нче биремне үтәүне сорый. **1 нче рәт** – күтәрелешнең 1 нче этабы, **2 нче рәт** – 2 нче этап, **3 нче рәт** 3 нче этап турында яза. Һәр рәттән бер укучы такта янына чыгып этаплар турында сөйли. Укытучы тарихи картадан восстание урыннарын күрсәтеп бара. Өйрәнелгән материал буенча фронталь сораштыру үткәрә.

Фетнәнең икенче этабы безнең төбәк белән бәйле була. 1774 елның 29 июлендә Пугачёв хәзерге Әгерҗе районы территориясенә килеп керә. Анда бер кич кунгач, Алабугага юл тота. 4 июльдә Нократ елгасын кичеп, Мамадышка аяк баса. *(Якташыбыз В.Галинең «Полковник Рахманкол» повестеннан өзекләр укый.)* 6 июльдә Пугачёв Казанга юл тота. *(Татарстан атласыннан Пугачёв гаскәренең юлын күрсәтергә куша.)* Күтәрелешнең тәмамлануы турында видеофрагмент күрсәтә. Эш дәфтәрендә **5 нче бирем:** күтәрелеш ничек тәмамлана? Е.Пугачёв белән нәрсә була? Дәрескә куелган бурычларның үтәлеше буенча йомгак ясала.

Укучыларга башкарган биремнәре буенча нәтиҗә ясарга куша.

*Укучылар эшчәнлеге:*

**танып белүдә:** материал белән танышканнан соң, укучылар мөстәкыйль яки парлап күтәрелешнең төп этаплары турында таблицаны тутыралар. Дәреслектәге картаны өйрәнәләр. Өйрәнгәннәре буенча такта янында җавап бирәләр, картадан күтәрелеш белән бәйле географик объектларны табалар.

Кинофрагментны караганнан соң, укучылар мөстәкыйль рәвештә күтәрелешнең нәтиҗәләре турында язалар. Укытучының сорауларына

җавап бирәләр.

Тарихи белемнәр алалар. Мөһим аспектларны билгели белү осталыгы, фактларны һәм вакыйгаларны анализлый белү сәләте үстерелә;

**регулятив эшчәнлек***:* мәгълүматны мөстәкыйль табалар. Укытучы сөйләмен максатчан тыңлыйлар, уку биремнәрен чишәләр, эш дәфтәрләрендәге биремнәренең үтәлешен бәялиләр.

Төп моментларны икенчелләреннән аера белү осталыгы, укучыларның фикерләү эшчәнлеге: гомумиләштерү, йомгак ясый белү сәләтләре үстерелә;

**коммуникатив эшчәнлек:** фронталь сораштыру вакытында укытучы белән контактка керәләр.

Укытучы һәм яшьтәшләре белән хезмәттәшлек иткәндә һәм аралашканда коммуникатив компетенцияләре формалаша, яхшыра.

**IV. Гамәли этап**

*Укытучы эшчәнлеге:*

партадаш белән үзара белемнәрен тикшереп карарга куша. Темага кагылышлы күрсәтмә материал өләшә, алардагы расламаларның дөреслеккә туры килү-килмәвен тикшерергә үтенә. Укучылар белән бергәләп тикшерә.

*Укучылар эшчәнлеге:*

**танып белүдә:** расламаларның дөреслеген тикшерәләр, фикер алышалар. Тарихи вакыйганың сәбәпләрен билгеләү осталыгы, йомгак ясый белү сәләте үстерелә;

**регулятив эшчәнлек:** уку материалының үзләштерелү дәрәҗәсен билгелиләр. Үзенең һәм башкаларның эшчәнлеген бәяләү сәләте үстерелә;

**коммуникатив эшчәнлек:** расламалар буенча фикер алышканда, үз карашын бәян итә. Сорауларга җавап биргәндә укытучы белән контактка керәләр.

Уку мәсьәләләрен чишкәндә, күмәк көчне туплый белү осталыклары, уртак фикергә килә алу сәләтләре үстерелә. Башкаларның фикере белән исәпләшү күнекмәләре, үз сөйләмнәрен дөрес кору осталыклары үстерелә.

**V. Рефлексив-бәя бирү этабы**

*Укытучы эшчәнлеге:*

укучыларга дәрестә өйрәнелгәннәр буенча үз фикерләрен әйтергә куша. Үз эшчәнлекләренә бәя бирүләрен үтенә. Моның өчен укучылар алдындагы төрле төсләрдәге карточкаларны күтәрүләрен үтенә: дәрестә барысын да аңласагыз – яшелен, әгәр дә аңлашылмаган сораулар калса – зәңгәрен, бернәрсә дә аңламаган булсагыз – кызылын күтәрәсез.

*Укучылар эшчәнлеге:*

**танып белүдә:** үзләренә туры килгән карточканы сайлыйлар. Үзләренең фикерләрен һәм теләкләрен җиткерәләр. Материалны анализлау һәм гомумиләштерү осталыклары үстерелә;

**регулятив эшчәнлек:** үз эшчәнлекләренә контроль ясыйлар һәм бәя куялар. Дәрестә ирешелгәннәрен бәялиләр.

Уку эшчәнлегенең уңышлылыгына карап үз эшчәнлегенә бәя кую осталыклары, ирешелгәннәренә карап, эмоциональ халәтләрен анализлый белү сәләте үстерелә;

**коммуникатив эшчәнлек:** үзара һәм укытучы белән контактка керәләр. Үз фикерләрен һәм тоткан позицияләрен формалаштыралар.

Үзләренең фаразларын әйтә һәм нигезләү осталыклары, яшьтәшләре һәм укытучы белән контактка бару осталыклары камилләшә.

**VI. Өй эше**

1. Дәреслектәге 21 нче параграфны укырга.

2. «Е.И.Пугачёв җитәкчелегендәге күтәрелеш» таблицасын тутырырга.

3. Күтәрелештә катнашучылар турында чыгышлар әзерләргә.

**Кулланылган чыганаклар**


1. Интернет материал Татарстанның электрон картасы «Татарлар Пугачёв хәрәкәтендә».

2. *Алишев С.Х.* Татары Среднего Поволжья в пугачёвском восстании. – Казань: ТКИ, 1973.

3. *Смирнов Ю.Н.* Современные подходы к истории восстания 1773 – 1775 гг. // Вестник СамГУ. – 2007. – № 5.

4. *Измайлов Б.* Емельян Пугачёв в Казани // Мәгариф. – №5. – 2022. – С. 77 – 79.

5. *Имамов В.* Сәет батыр. Татарлар Пугачёв явында: Тарихи роман һәм тарихи очерк. – Чаллы: «КамАЗ» нәшр., 1994. – 512 б.


***

*Тирән эчтәлекле тарихи язмалары белән журналыбыз битләрендә актив катнашып килгән Ринат Миңлегаян улы Хәйруллин – чын мәгънәсендә «коеп куйган мәгърифәтче-мөгаллим». Аның Ризаэддин Фәхреддин исемендәге республика премиясе лауреаты дип танылуы да – моңа ачык дәлил. Алабуга дәүләт педагогия институтының гомуми техник фәннәр факультетын тәмамлагангамы, җитмеш җиде төрле һөнәр иясе дә әле ул. Студент вакытыннан башлап, ничә еллар җәйге чорда комбайн штурвалын иярләде. Хезмәт укытучысы булып дистә еллап эшләгәннән соң, 1993 елдан яшь буынга тарих һәм җәмгыять белеме дәресләрен укыта башлый. Тарихи Кирмән шәһәрлеге төбәгендә яшә дә, тарих белән ничек кызыксынмасын да укучылары күңелендә туган ягының бай тарихы белән кызыксыну уятмасын, ди. Үз табыш-эзләнүләрен кәгазьгә төшереп, үтемле язмалары аша татар матбугаты басмалары, шул исәптән «Мәгариф» журналы укучылары белән дә уртаклашырга да вакыт таба Ринат Миңлегаян улы. Журналыбыз битләрендә урын алган язмаларының исемнәре үк укучы күңелен җәлеп итәрлек. Менә аларның кайберләре: «Туган ягыбыз тарихын өйрәнәбез», «Без коррупциягә каршы», «Аттестация куркыныч түгел», «Ни өчен яшь укытучылар мәктәптән китә?», «Җәмгыять белеме дәресләрендә халык педагогикасы элементлары», «Академик Курчатов Казанда», «Батырлыгың тиңсез синең, Ленинград», «Икътисадның төп мәсьәләләре», «ТАССРда индустриаләштерү», «Татарстан – уртак йортыбыз», «1100 еллык тарих эзеннән»... Ринат әфәнденең каләме үткер һәм йөгерек телле, дәлилле. Юкка гына ул Татарстан һәм Россия Журналистлар берлекләрендә әгъза булып тормый шул. Шуңамы журналыбыз оештырган иҗади конкурсларда аның язмалары жюри тарафыннан югары бәяләнә. Әйтик, ул «Тарих дәресе: ТАССРга – 100 ел» конкурсының абсолют җиңүчесе дип табылды.*

*Быел инде мөхтәрәм авторыбыз Ринат әфәнде Хәйруллин 38 нче уку елын туган мәктәбендә каршылады. Әле шуның өстенә 24 сентябрьдә гомер бәйрәмен дә билгеләп үтә. Редакция коллективы һәм «Мәгариф» журналы укучылары исеменнән аны 60 яшьлек олуг юбилее белән ихластан котлыйбыз, аның киләчәктә дә егетләрчә янып яшәвен, иҗат дәртенең сүрелмәвен телибез.*

# Русь дәүләте һәм Бату хан

*(6 нчы сыйныфта тарих дәресе)*



**Гөлнара ЗАҺИДУЛЛИНА,**
*Буа районы Иске Суыксу урта мәктәбенең тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы*

**Максат:** укучыларда Бату хан яулары турында күзаллау булдыру һәм илнең киләчәк тарихындагы әһәмиятен ачыклау.

**Бурычлар:**

– Русь җирләрен яулап алуның үзенчәлекләрен аңлату;

– Русь җирләренең монголлар хакимлеге астында калу сәбәпләрен ачыклау.

**Көтелгән нәтиҗәләр**

*Предмет:* XIII гасыр уртасында Русьның тарихи юлы турындаербөтен күзаллауга ия була; монгол империясенең үсеш үзенчәлекләрен тасвирлый; төшенчәләр аппараты куллана белә; рус һәм монгол сугышчыларының охшашлыгын һәм аерымлыгын билгели; тарихи вакытны һәм тарихи киңлекне үзара яраштыра; тарихи шәхесләрнең хәрәкәт һәм гамәлләрен чагыштыра; төрле чыганаклардагы мәгълүматны чагыштыра һәм системага сала.

*Коммуникатив:* үз эшчәнлеген планлаштыра һәм көйли; монологик контекстлы сөйләмгә ия була; индивидуаль һәм төркемләп эшләү барышында укыту күнекмәләрен үстерә.

*Регулятив:* укучы яңа максат һәм бурычлар куярга өйрәнә; укучы максатка ирешүне планлаштыру, аның чараларын һәм шартларын үзлегеннән таба белү мөмкинчелеге ала, үзанализ һәм үзбәя булдыра.

*Танып белү:* укучы дәреслек, электрон ресурслар, документ материалы кулланып, сорауларга җавап бирергә өйрәнә; сәбәп-нәтиҗә бәйләнеше булдыру мөмкинчелеге ала; үз фикерен исбатлый һәм яклый алырга өйрәнә.

*Шәхескә карата:* Россия тарихын өйрәнүгә кызыксыну формалаштыра һәм үстерә, тарихи мираска хөрмәт белән карый; тарихи вакыйгаларны һәм тарихтагы шәхесләрнең ролен бәяли; ватанпәрвәрлек хисләрен тәрбияли, Ватаныбызны яклаучылар үрнәгендә патриотизм идеяләрен ача.

**Дәреснең технологик картасы**

| Дәрес этабы | Укытучы эшчәнлеге | Укучылар эшчәнлеге | УУГ |
|---|---|---|---|
| **I. Оешты-ру өлеше** Уңай психоло-гик халәт булдыру. Өй эшен тикшерү | – Хәерле көн, укучылар! Үткән дәрестә без сезнең белән «Русь җирләре XIII гасыр уртасында – XIV гасырда» дигән бүлекне өйрәнә башладык, «Азиядә һәм Европа чикләрендә монголлар явы. Калка елгасы буендагы сугыш» темасын уздык. **(1 нче слайд)** Бу тема буенча иң мөһим вакыйгалар ниндиләр? | Укытучыны, сыйныфташларны сәламләү. – Монгол империясенең барлыкка килүе, Чыңгыз ханның хәрби походлары. Монголлар белән русларның сугышы, монголларның Руська бәреп керүе; Калка елгасы буенда бәрелеш. | *Шәхси:* – укытуга әзерлек (игътибарны җәлеп итү); – дәреснең барлык этапларында ирекле тәртип булдыру. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Үткән дәрес темасын түбәндәге план нигезендә искә төшерик:<br>1. Монголлар империясе төзелү.<br>2. Чыңгыз хан походлары.<br>3. Калка елгасы буенда сугыш. **(2 нче слайд)**<br>*http://vivl.ru/genghis/mongol.php карта буенча эш.*<br>**Нәтиҗә.** XIII гасыр башында бик көчле, нык монгол империясе төзелә, аның идарәчесе Чыңгыз хан үз дәвамчыларына «соңгы диңгезгә чаклы барып җитегез» дигән васыятен калдырган.<br>**(3 нче слайд)**<br>– «Соңгы диңгезгә чаклы барып җитегез» дигәнне, укучылар, сез ничек аңлыйсыз?<br>*http://vivl.ru/genghis/mongol.php:*<br>– Монгол империясе җирләрен картадан күрсәтегез. Сезнеңчә, соңгы диңгез кайда ул? Атлантик океанга юл кайсы дәүләт аша уза? Нинди нәтиҗә ясап була? | – Бик күп җирләрне яулап алу, бөтен дөньяны буйсындыру. | |
| **II. Дәрес темасын билгеләү** | – Димәк, без сезнең белән нәрсәләр турында сөйләшербез?<br>– Бик дөрес, укучылар! Чыңгыз ханның васыятен аның оныгы Батый (Бату) хан үтәргә булган, шуңа күрә дәресебезнең темасы да «Русь дәүләтенә Бату хан явы» дип аталачак. Дәфтәрләргә бүгенге датаны, дәрес темасын язып куегыз.<br>**(4 нче слайд)** | – Монголларның яулап алуларының дәвам итүе турында. | |
| **III. Белемнәрне актуальләштерү. Дәрес максатын билгеләү** | – Теманы өйрәнгәнче, искә төшереп узыйк: бу чорда Русь сәяси яктан нинди була? Карта буенча эш: *http://library.ispu.ru:8001/HISTORY/1/03tema3/karti3/08razdroblenn.html*<br>– Чыннан да. Менә шул бердәмлек булмаудан, Русь дәүләтенең обороносы нык булмаудан Бату хан файдаланып калырга уйлый һәм максатын тормышка ашыра.<br>– Дәресебезнең максаты нинди булыр икән? **(5 нче слайд)**<br>– Бүгенге теманы түбәндәге план буенча өйрәнербез:<br>1. Рязань җиренә бәреп керү.<br>2. Владимир кенәзлеген туздыру.<br>3. Новгородка яу чабу.<br>4. Көньяк-Көнбатыш Русь һәм Үзәк Европага бәреп керү. **(6 нчы слайд)** | – XIII гасыр башында Русь сәяси таркаулык хәлендә була. Калка елгасы буендагы сугыш вакытында таркаулык тагын да чагыла, чөнки рус кенәзләре үзара килешеп хәрәкәт итмиләр, гел бәхәсләшеп, хәлне тагын да катлауландыралар.<br>– Ни өчен Русь дәүләте монголлар изүенә бирешкән? Бату хан яуларының уңыш сере нидә? | *Предмет:* тарихи вакытны һәм тарихи киңлекне чагыштыру.<br>*Регулятив:* уку бурычын кабул итү.<br>*Коммуникатив:* үз фикерләрен белдерү.<br>*Танып белү:* дәрес максатын мөстәкыйль ачыклап формалаштыра алу.<br>*Шәхси:* Россия тарихын өйрәнүгә кызыксыну формалаштыру. |
| **IV. Яңа тема буенча эш** | – Теманы өйрәнгәнче, Бату хан турында мәгълүмат белән танышып китик: *http://www.hrono.info/biograf/bio_b/batyi.php (русча)*<br>*http://tatarile.tatar/tt/encyclopedia/batu (татарча)*<br>– Дәрес материалын төркемнәргә бүленеп өйрәнербез.<br>**1 нче төркем.** Рязань җиренә бәреп керү.<br>**2 нче төркем.** Владимир кенәзлеген туздыру һәм Новгородка яу чабу.<br>**3 нче төркем.** Көньяк-Көнбатыш Русь һәм Үзәк Европага бәреп керү.<br>– Төркемнәрдә өч төрле бирем эшләрбез:<br>1. 16 нчы параграф тексты һәм иллюстрацияләре белән эш.<br>2. Тарихи документ белән эш.<br>3. Карта белән эш. *(Төркемнәрдә эш барышы –7–10 мин.)* | | *Регулятив:* бирелгән күрсәтмә (эталон) белән чагыштыру, үз эшчәнлегеңне оештыру.<br>*Коммуникатив:* үз фикереңне аргументлаштыру.<br>*Танып белү:* аңлы рәвештә дөрес итеп сөйләмеңне формалаштыру, билге һәм символлар кулланып эш итә белү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | Төркемнең спикеры эшләнелгән эш буенча чыгыш ясый. *(Эш тәртибе һәр төркемнең өстәлендә.)*<br>**1 нче төркем биремнәре:**<br>1. Дәреслектәге §16 ның 12–13 нче битләрендәге 1 нче пунктны укып чыгасыз. Бирем текстында төшеп калган сүзләрне язасыз.<br>12 нче биттәге иллюстрация буенча монголларның Рязаньны камавы турында сөйләргә әзерләнәсез.<br>**Текст**<br>*Беренче һөҗүм ... декабрендә ... кенәзлегенә ясала. Рязань кенәзе ..., ... күрше кенәзлекләреннән ярдәм сорый, әмма алар ярдәм итүдән баш тарталар. ... хан Рязань җирендә яшәүчеләргә «җирегездә булган бөтен нәрсәнең уннан бер өлешен бирегез» дигән таләп куя. Рязань кенәзе Батый ханга бик күп бүләкләр тапшыра. Әмма Батый хан тагын да каты таләпләр куя, болар белән кенәз килешми. Шул сәбәпле, монголлар шәһәрне камап ала. ... көн шәһәр халкы монголлар һөҗүменә каршы тора, ләкин ... декабрьдә бирелергә мәҗбүр була. Шәһәр яндырыла. Исән калган Рязань кешеләре, бояр ... җитәкчелегендә, дошман белән озак сугыш алып бара.*<br>2. §16 ның 13 нче битендәге тарихи документны өйрәнеп, рус халкының батырлыгы турында хикәя төзегез.<br>3. Дәреслекнең 16–17 нче битләрендәге карта буенча Бату хан походы юнәлешләрен өйрәнегез.<br>**2 нче төркем биремнәре:**<br>1. Дәреслектәге §16 ның 14–15 нче битләрендәге 2, 3 нче пунктларны укып чыгасыз. Бирем текстында төшеп калган сүзләрне язасыз.<br>12 нче биттәге иллюстрация буенча монголларның Владимир, Новгород җирләрендәге шәһәрләргә яу чабуы турында сөйләргә әзерләнәсез.<br>**Текст**<br>*Рязаньнан соң Мәскәү бирелә. ... елның февраль башында Батый хан ... шәһәренә килеп җитә. Шәһәрне камаган вакытта, монголлар ... һәм ... җайланмалары куллана. Владимирны саклау воевода ... кулына тапшырыла. Шәһәр халкы, кенәз гаиләсе ... соборына кача, әмма ул яндырыла. 1238 елның март ахырында монголлар кечерәк ... шәһәре янына килеп җитә. Шәһәр кешеләре (... чамасы) каршылык күрсәтә. Батый хан Козельскины «...» дип атый һәм җир белән тигезләргә куша.*<br>2. «Юрий Всеволодович һәм Василько Константинович» дигән тарихи документ белән танышып, рус халкының батырларча каршылыгы турында хикәя төзегез.<br>3. Дәреслекнең 16–17 нче битләрендәге карта буенча Бату хан походы юнәлешләрен өйрәнегез.<br>**3 нче төркем биремнәре:**<br>1. Дәреслектәге §16 ның 12–13 нче битләрендәге 1 нче пунктны укып чыгасыз. Бирем текстында төшеп калган сүзләрне язасыз, Көньяк-Көнбатыш Русь һәм Үзәк Европага бәреп керү турында сөйләргә әзерләнәсез. | Төркемнәрдә бирелгән биремнәрне башкаралар.<br><br>Төркемнәрнең чыгышлары. | *Шәхси:* тарихи вакыйгаларны һәм тарихтагы шәхеснең ролен бәяли белү; Ватанны саклаучылар үрнәгендә ватанпәрвәрлек хисе тәрбияләү. |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | **Текст**<br>*Батый хан яңа походка әзерләнә башлый. Максаты – көньяктагы рус җирләрен генә түгел, ә ... да үзенә буйсындыру. ... елда ..., ... һәм башка шәһәрләр басып алына һәм яндырыла. ... елның сентябрендә Бату гаскәре ... чолганышка ала. Киевны саклау белән воевода ... җитәкчелек итә. ... дәвамында Киев камалып торганнан соң, бирелергә мәҗбүр була. ... елның язында Бату хан Галич-Волынь Русе, Венгрия, Польша, Чехия, Хорватия җирләренә юл тота. Әмма ... елда Бату кирегә борылырга боерык бирә. Чыңгыз ханның васыяте үтәлми кала.*<br>2. «Киевны алу турында Ипатьево елъязмасы» («Ипатьевская летопись о взятии Киева») исемле тарихи документ белән танышып, рус халкының батырларча каршылыгы турында хикәя төзегез.<br>3. Дәреслекнең 16–17 нче битләрендәге карта буенча Бату походы юнәлешләрен өйрәнегез. | | |
| **V. Туган кыенлыкны табу, чыгу юллары** | – Дәрестәге хезмәтегез өчен бик зур рәхмәт. Ә хәзер теманы өйрәнер алдыннан бирелгән сорауларга җавап биреп карыйк.<br>Ни өчен Русь дәүләте монголлар изүенә бирешкән? Бату хан яуларының сере нидә?<br>**Русь дәүләтенең бирелү сәбәпләре:**<br>1. Сәяси таркаулык.<br>2. Бердәм армия булмау.<br>3. Рус дружинасының кораллану ягыннан артта калганлыгы.<br>**Монголларның уңышка ирешү сәбәпләре:**<br>1. Сан ягыннан күп булуы.<br>2. Ныклы дисциплина, басып алу тактикасы, разведка.<br>3. Хәрби-техник яктан алга киткән булуы.<br>– Бату походларыннан соң Русьта монголлар бәйлелегендә яшиләр (Алтын Урда изүе).<br>– 1237–1240 елларны сез ничек дип атар идегез? | | *Регулятив:* үзбилге.<br>*Коммуникатив:* әйтелгән фикерне аргументлаштыра алу.<br>*Танып белү:* логик фикерләп, нәтиҗәләр ясый алу. |
| **VI. Дәрес материалын үзләштерүне тикшерү** | – Бүгенге теманы ничек үзләштердегез икән, тест эшләү.<br>1. Кодлы тест *(кушымтада).*<br>2. *https://uchi.ru/homeworks/teacher/new?stage=init&tt=JOB&s=13&p=6&titlePath=7761&titlePath=7765* (учи.ру платформасында эш). | Тестларны эшлиләр. | |
| **VII. Рефлексия** | **«Светофор»:** укучылар төрле төстәге түгәрәкләрне тактага беркетә:<br>– *яшел түгәрәк* – шундый эчтәлекле, мөһим дәресләр күбрәк булсын иде;<br>– *сары* – ошады, әмма барысы да түгел;<br>– *кызыл* – кирәкле материал түгел. | | |

**VIII. Өй эше**
1. Дәреслектәге 16 нчы параграфны укырга.
2. Контурлы картада Бату хан яулары юнәлешләрен, шәһәрләрен билгеләргә.
3. https://edu.skysmart.ru/student/patexupili сылтамасы буенча интерактив биремнәрне эшләргә.

# Мин – Татарстан гражданы: хокукларым һәм бурычларым

*(Татарстан Республикасы Конституциясенең 30 еллыгына багышланган Парламент дәресе)*



**Лидия КОНСТАНТИНОВА,**
*Мамадыш районы Усали урта мәктәбенең тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы*

**Максат:**

– Конституциянең җәмгыятьтәге роле, илебез һәм республикабыз гражданнарының Конституцияләрдәге хокуклары һәм бурычлары турында сөйләшү;

– хокукый культура нигезләрен булдыру өстендә эшләү;

– гражданлык, патриотизм, законга хөрмәт тәрбияләү;

– Татарстан Республикасы Конституциясенең әһәмиятен күрсәтү.

**Җиһазлау:** Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Конституцияләре, дәрескә презентация.

**Дәрес барышы**

**I. Кереш**

**Укытучы.** Хәерле көн, укучылар! Без ел саен сезнең белән Парламент дәресенә җыелабыз. Һәрберегезнең партасында Конституцияләр ята. Ничек уйлыйсыз, быелгы дәреснең темасы нинди булыр икән?

**Укучылар.** «Конституция – төп законыбыз!», «Гражданнарның хокуклары һәм бурычлары» һ.б.

**Укытучы.** Дөрес. Быелгы дәреснең темасы «Мин – Татарстан гражданы: хокукларым һәм бурычларым» дип атала.

Сезнең алдыгызда Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы Конституцияләре ята. Ачып карамыйча гына, бу китапларны тотып карагыз әле. Кайсысы калынрак?

**Укучылар.** Татарстанныкы!

**Укытучы.** Ни өчен республикабыз Конституциясенең күләме зуррак икән?

**Укучылар.** Чөнки ул ике телдә – рус һәм татар телләрендә язылган, чөнки бездә ике дәүләт теле.

**Укытучы.** Бик дөрес. Хәзер бу Конституцияләрнең кабул ителү вакытларына игътибар итегез.

**Укучылар.** Россия Федерациясе Конституциясе 1993 елның 12 декабрендә, ә Татарстан Республикасы Конституциясе 1992 елның 6 ноябрендә кабул ителгән. Димәк, республикабыз Конституциясе бер ел алдан кабул ителгән булган.

**Укытучы.** Тагын нәрсәгә игътибар иттегез?

**Укучылар.** Узган ел республикабыз Конституциясенең кабул ителүенә 30 ел тулды. Быел исә – Россиянекенә.

**Укытучы.** Афәрин! Мин аңлап бетермим әле, укучылар, субъектлардагы төп законнар Россия Федерациясе Конституциясенә каршы килергә тиеш түгел

дип өйрәнәбез. Татарстан Конституциясен төзүчеләрнең алдында илебезнең төп законы булмаган бит. Аның ничек Россия Конституциясенә каршы килмәслек итеп эшләп булды икән?

**Укучылар.** Аңа кабат, Россия Конституциясенә яраклаштырып, төзәтмәләр керттеләр.

**II. Төп өлеш**

**Укытучы.** Дөрес. Искә төшерик әле, нәрсә соң ул Конституция?

**Укучылар.** Конституция – илнең төп законы. Ул җәмгыять һәм дәүләтнең төзелешен, хакимият органнарын оештыру тәртибен һәм принципларын, сайлау системасын, гражданнарның төп хокукларын һәм бурычларын билгели.

**Укытучы.** Конституция нәрсәгә кирәк?

**Укучылар.** Илдә законсызлык була алмый. Илдә бөтен законнар Конституция нигезендә генә кабул ителә ала. Дәүләттә төп законга каршы килүче башка законнар кабул ителмәскә тиеш. Чөнки ул иң югары юридик көчкә ия.

**Укытучы.** Тагын шуны өстәп әйтергә кирәк: Конституция кешегә туган илендә үзен чит кеше итеп тоймас өчен дә кирәк. Кеше үзен шушы илнең тулы хокуклы гражданы итеп тоярга тиеш.

Сез ничек уйлыйсыз, безгә ике Конституция нигә кирәк? Россия Федерациясе Конституциясе генә җитмимени?

**Укучылар.** Без федератив дәүләттә яшибез. Башка халыкларга толерант мөнәсәбәттә булсак кына без уңышларга ирешә алачакбыз. Федерация берләшмә, килешү дигәнне аңлата.

**Укытучы.** Россия Федерациясе субъекты ни дигән сүз?

**Укучылар.** Бу – илебездә тигез, тулы хокуклы өлкә дигән сүз.

**Укытучы.** Дөрес, яхшырак аңлау өчен, түбәндәге таблицага күз салыгыз:




**Укытучы.** Алда әйтелгәннәрдән чыгып, нәтиҗә ясыйбыз:

> Россия Федерациясе субъектлары үзләренең төп законнарына ия. Аларның үз вәкаләтләре бар. Ләкин алар илебезнең төп законы – Россия Федерациясе Конституциясенә каршы килергә тиеш түгел.

**Укытучы.** Хәзер, укучылар, Татарстан Республикасы Конституциясенең преамбуласына күз салыйк. Нәрсә ул преамбула? Ул – кереш өлеш, кереш сүз дигән сүз. Анда законнар язылмаган. Ләкин ул Конституциянең эчтәлегенә кереш булып тора, аның төп принципларын билгели.

**Укучылар** *(укыйлар).* Әлеге Конституция Татарстан Республикасының күпмилләтле халкы һәм татар халкының ихтыярын чагылдырып,

– кеше һәм граждан хокукларының һәм ирекләренең өстенлеген гамәлгә ашыра;

– халыкларның гомумтанылган үзбилгеләнү хокукына, аларның тигез хокуклыгына, ихтыяр белдерүнең ирeклелеге һәм бәйсезлеге принципларына нигезләнә;

– тарихи, милли һәм рухи традицияләрнең, мәдәниятләрнең, телләрнең сакланып калуына һәм үсешенә, гражданнар татулыгын һәм милләтара килешүне тәэмин итүгә ярдәм итә;

– федерализм принципларында демократиянең ныгуы, Татарстан Республикасының социаль-икътисади үсеше Россия Федерациясе халыкларының тарихи барлыкка килгән бердәмлеген саклап калу өчен шартлар тудыра.

**Укытучы.** Татарстан Республикасы Конституциясе 7 кисәктән, 4 бүлектән, 126 маддәдән (статьядан) тора. Һәр Конституциядәге кебек, анда да гражданнарның хокуклары, ирекләре, бурычлары турында маддәләр бар. Бурычлар һәм хокукларның нинди төрләргә бүленүен искә төшереп китик әле.

**ГРАЖДАНИННЫҢ ХОКУКЛАРЫ ҺӘМ ИРЕКЛӘРЕ**

| **шәхси (гражданлык)** | **сәяси** | **социаль-икътисади һәм мәдәни** |
|---|---|---|
| яшәүгә, тормышка | берләшмәләрдә торырга | эшмәкәрлек ирегенә |
| шәхес ирегенә | сәяси тормышта катнашырга | шәхси милеккә |
| вөждан ирегенә | сайларга һәм сайланырга | хезмәткә |
| сүз һәм фикер ирегенә | дәүләт органнарына мөрәҗәгать итәргә | гаилә төзүгә |
| милли мәдәнияткә | мәгълүмат алырга, таратырга хокук | социаль тәэмин ителүгә |
| тору һәм яшәү урынын сайларга | | торакка |
| | | сәламәтлекне саклауга |
| кешеләр белән берләшергә | | |

**Укытучы.** Татарстан Республикасы Конституциясенең 2 нче маддәсе белән танышыйк әле, укучылар.

**Укучылар.** Кеше, аның хокуклары һәм ирекләре – иң зур хәзинә. Кеше һәм гражданин хокукларын һәм ирекләрен тану, үтәү һәм яклау – Татарстан Республикасының бурычы.

**Укытучы.** Инде 8 нче маддәгә игътибар итик.

**Укучылар.** Татарстан Республикасында дәүләт телләре – тигез хокуклы татар һәм рус телләре.

**Укытучы.** Хәзер 26 нчы маддә белән танышып китик.

**Укучылар.** 1. Һәркем үзенең кайсы милләттән булуын билгеләргә һәм күрсәтергә хокуклы. Беркем дә үз милләтен билгеләүгә һәм күрсәтүгә мәҗбүр ителә алмый.

2. Һәркем ана теленнән файдаланырга, аралашу, тәрбия, уку һәм иҗат итү телен ирекле сайлап алырга хокуклы.

**Укытучы.** Укучылар, 37 нче маддәнең дә эчтәлеген аңлау кирәк.

**Укучылар.** 1. Һәркемгә вөждан иреге, дин тоту иреге, индивидуаль яисә башкалар белән бергә теләсә нинди динне тоту яисә берсен дә тотмау хокукын да кертеп, дини һәм башка төрле инануларны ирекле сайлап алу, аларга ия булу һәм аларны тарату, шулар нигезендә эш итү гарантияләнә.

2. Дин тотуга бәйле рәвештә дошманлык, нәфрәт һәм милли ызгыш кузгату тыела.

**Укытучы.** 62 нче маддә һәркемнең табигатьне сакларга тиешлеге турында булса, 63 нче маддәдә гражданнарның хәрби хезмәт үтәргә тиешлелеге турында язылган. Шулай ук Конституциябездә дәүләт символлары турында да маддә бар. Ул 121 нче сан белән бара.

Укучылар, без бүгенге Парламент дәресендә хокукларыбыз һәм бурычларыбыз турында да сөйләштек. Ә кем соң ул гражданин? Бу сорауга җавап бирмәдек шикелле.

**Укучылар.** Гражданин ул – шушы илдә яшәүче. Конституцион хокуклардан файдаланучы. Туган илен яратучы һ.б.

**Укытучы.** Барысы да дөрес, укучылар. Бу сүзнең эчтәлеген тирәнрәк аңлау өчен, сүзне иптәшләрегезгә бирик. Ә сез игътибар белән тыңлагыз.

**Укучылар** *(А. Безденежных тексты берничә укучыга бүлеп бирелә).*

– Ил гражданины Туган илен бик ярата диләр. Ә нәрсә соң ул Ватан? Сандугачлы каен урманымы? Кызганыч, шул матур урманда чүп өемнәрен калдыралар. Тирә-ягыбызда ярлы, хәтта хәерче кешеләр бар. Ә бәяләр? Кемнәрнеңдер торыр урыны юк. Тагын да куркынычы шул: күпме егетләребез Әфган, Чечня сугышларында ятып калган... Уйлап карыйк әле, гражданин шушы хәлләрне яратырга тиешме? Юк инде, үз хөкүмәте, үз халкы җибәргән ялгышларны яратып булмый. Әмма гражданин үз илен яратырга тиеш.

– Ул, бу хәлләргә борчылып кына калмыйча, боларны булдырмас өчен үз сүзен

әйтергә тиеш. Ул үзгәртеп корулар, тәртип салуны таләп итәргә тиеш. Илебездәге сайлауларда катнашмый торып, тормышны үзгәртеп булмаячагын аңларга тиеш.

– Гражданин салымнарын вакытында түләргә бурычлы, чөнки бу акчалар ятим балаларга, авыруларга, хәерчеләргә булыша, аңа юллар, хастаханәләр төзелә.

– Гражданин Ватан алдындагы бурычын үтәргә тиеш.

– Гражданин табигатьнең үлә баруына юл куймаска, кулына көрәк алып, агачлар утыртырга тиеш.

– Гражданин мәдәни мирасны юкка чыгаручылар белән килешмәскә, тарихи биналарны сүтүгә каршы чыгыш ясарга тиеш.

– Гражданинны базарда сатучы алдаса, дәшми калырга тиеш түгел ул. «Кулланучылар хокукын яклау турында»гы Закон нигезендә гаделлекне табарга тиеш.

– Гражданин урлауга, «акча төртү»гә юл куярга тиеш түгел.

– Гражданин аракы һәм наркотиклар аркасында халыкның үлүенә битараф түгел. Ул хөкүмәтебездән кискен чаралар таләп итәргә тиеш.

**Укытучы.** Укучылар, менә кем ул чын гражданин!

**Укытучы.** Укучылар! Без, әлбәттә, бер дәрес белән генә бөтен Конституцияне өйрәнеп чыга алмаячакбыз. Гербыбыз, флагыбыз, гимныбызны өйрәнгән кебек, Конституциябезне дә өйрәнү кирәк. Без аның белән танышуны җәмгыять белеме дәресләрендә дәвам иттерербез әле. Ә бүгенге дәрескә йомгакны үзегез ясап карагыз әле. Нинди нәтиҗәләр ясарбыз?

**III. Йомгаклау**

**Укучылар.**

– Без Россия Федерациясенең Татарстан Республикасы дигән субъектында яшибез. Безнең үз Конституциябез бар.

– Тормышта үз хокукың һәм ирекләреңне белү мөһим.

– Кеше үз хокукларын белгәндә генә дөреслекне таба ала.

– Конституцияне белү безгә бердәм дәүләт имтиханнарын тапшыруда ярдәм итә.

– Татарстан Конституциясе безгә милләтебезне, телебезне саклауда төп таяныч булып тора.

– Илебезнең лаеклы гражданы булу өчен ниләр кирәклеген белдек.

*(Дәрес Татарстан Республикасы гимнын (Р.Байтимеров сүзләре, Р.Яхин көе) язмага кушылып, басып җырлау белән тәмамлана.)*



# Без – Россиянең киләчәге

*(7 – 9 нчы сыйныф укучылары өчен эшлекле уен)*

**Алсу ГАЗЕТДИНОВА,**
*Актаныш районы Такталачык төп мәктәбенең тарих һәм җәмгыять белеме укытучысы*

**Максат:** укучыларда актив гражданлык, патриотлык хисләре тәрбияләү; хокукый культура, дәүләт төзелеше, хокук, кеше хокуклары турында нигезле белемнәр формалаштыру; аларның иҗади активлыгын стимуллаштыру.

**Эшлекле уен барышы**

**Укытучы.** Хәерле көн, укучылар, укытучылар! Бүген бездә – «Без – илнең киләчәге» эшлекле уены. Без бүген хокукый культура, патриотлык, Россия тарихы, хокук, кеше хокуклары хакында искә төшерербез. Эшлекле уенда ике команда катнаша. Барлык конкурслардан соң күбрәк очко җыйган команда җиңүче була.

**1 нче тур – «Командаларны сәламләү»**

**Укытучы.** Уеныбызны танышудан башлыйк. *(Командалар исемнәрен, девизларын әйтәләр. Таныштыру өлешенә максимум 5 балл бирелә.)*

Безгә ярдәмгә хөкемдарлар да кирәк. *(Хөкемдарлар билгеләү.)*

Безнең чара Россиягә багышланган. Үз илебезнең чын патриотлары буларак, мин һәркемгә бергә РФ гимнын башкарырга тәкъдим итәм.

*(Гимн яңгырый.)*

**2 нче тур – «Сез ышанасызмы?»**

**Укытучы.** Бирелгән сорауларга «әйе» я «юк» дип җавап бирергә кирәк. Үтәү вакыты – 3 минут. Язма рәвештә эшләп жюрига тапшырасыз. *(Һәр дөрес җавап 1 балл белән бәяләнә.)*

| Сез ышанасызмы? | Җавап |
|---|---|
| Мәскәү турында беренче мәгълүмат 1147 ел белән бәйле | Әйе |
| Россиянең гамәлдәге Конституциясе 1995 елда кабул ителгән | Юк, 1993 елда |
| Россиядә 1118 шәһәр бар | Әйе |
| 4 декабрь – Халыклар бердәмлеге көне | Юк, 4 ноябрьдә |
| Россиядә 250 төрле милләт яши | Юк, 190 |
| Россия дөньяның 18 дәүләте белән чиктәш | Әйе |
| 25 яшьтән президент булырга мөмкин | Юк, 35 яшьтән |
| Россиядә законнар хөкүмәттә барлыкка килә | Юк, парламентта |

**3 нче тур – «60 секунд хокук тирәсендә»**

Чират буенча һәр команда чакырыла. Команда 1 минут эчендә алып баручы биргән

сорауларга җавап бирергә тиеш. Уйлау вакыты 5 секундтан артмый. *(Һәр дөрес җавап өчен 1 балл бирелә.)*

1. Хокук барлыкка килгән шәһәр. *(Рим)*

2. Милләтне юк итүгә юнәлтелгән гамәлләр. *(Геноцид)*

3. Биналарны, зиратларны яки башка корылмаларны бозу. *(Вандаллык)*

4. Дәгъва белдерүче кеше яки орган. *(Дәгъвачы)*

5. Конкрет затны җинаять җәзасыннан азат итү буенча РФ Президенты акты. *(Амнистия)*

6. Зыян китерү өчен төрле объектларны шартлату, яндыру яки башка ысул белән җимерү. *(Диверсия)*

7. Судта дәүләт гаепләүчесе. *(Прокурор)*

8. Президентны вазифасыннан алу. *(Импичмент)*

9. Товар, башка әйберне таможня чиге аша законсыз чыгару. *(Контрабанда)*

10. Төзәтү учреждениесе төре. *(Колония)*

11. Суд карары буенча мөлкәтне бушлай алу. *(Конфискация)*

12. Дәүләт белән идарә итү формалары. *(Республика һәм монархия)*

13. Белә торып ялган мәгълүмат тарату. *(Яла)*

14. Файда алу максаты белән алдау. *(Мошенниклык)*

15. Гадел хөкем чыгаручы орган. *(Суд)*

16. Гражданлыкны сайлау. *(Оптация)*

17. Аеруча мөһим норматив-хокукый актларга кыскача кереш сүз. *(Преамбула)*

18. Никах теркәү урыны. *(ЗАГС)*

19. Дәүләтнең төп законы. *(Конституция)*

20. Мөһим мәсьәләләр буенча бөтенхалык тавыш бирүе. *(Референдум)*

**4 нче тур – «Фильмны танийсызмы?»**

**Укытучы.** Укучылар, сезгә алдан өй эше буларак Россия, аның тарихы турында фильм һәм мультфильмнар карарга кушылган иде. Хәзер алардан өзек карап, исемен әйтергә тиеш буласыз. Һәр фильмнан 2 минутлык өзек күрсәтелә. Сораулар ике команда өчен дә уртак. Кем өлгер, шул җавап бирә. *(Дөрес җавап 1 балл белән бәяләнә.)*

**1. «Романовлар» фильмыннан өзек**

Михаил Фёдоровичның патшалыкка сайлануының 400 еллыгына багышланган фильм Романовларның Россия, дөнья тарихы вакыйгаларында роле турында.

**2. «Бөек Себер юлы» фильмыннан өзек**

Бу фильмда фотограф Л. Круглов Арктика тикшерүчесе С. Дежнёв эзләре буенча сәяхәткә китә. Фильм-сәяхәт 4 ел дәвамында төшерелгән. 10 мең км кабатланмас матурлык һәм сынау – Архангельскидан Беринг бугазына кадәр.

**3. «Беренче бөтендөнья сугышы» (2014) фильмыннан өзек**

Бу документаль тарихи картина беренче бөтендөнья сугышының Россия империясендә кешеләр тормышын ничек үзгәртүен күрсәтә. Бу – геройлар һәм патриотизм, ул сугышның авыр сынаулары, газаплары

турында фильм. Одессада туып үскән Родион исемле малай биографиясен бөтен кино дәвамында күзәтергә мөмкин. Ул – булачак маршал һәм ике тапкыр Советлар Союзы Герое Родион Малиновский.

**4. «Бөек сугыш» фильмыннан өзек**

Әлеге документаль драма тарихи реконструкция форматында төшерелгән, анда Бөек Ватан сугышының төп чорлары, сугышлары күрсәтелгән. Сугыш елларының чын видео – һәм фотохроникасы тамашачыны сугыш чоры атмосферасына чумдыра. Фильм буенча вакыйга, даталарны өйрәнергә, илебез тарихында XX гасырның иң масштаблы фаҗигасенә үтеп керергә мөмкин.

**5. «Белка һәм Стрелка» мультфильмыннан өзек**

Мультфильм Космонавтлар әзерләү үзәгендә сайлап алынган һәм, Американы узып, космоска очкан ике эт турында сөйли. 1960 елның реаль вакыйгалары буенча төшерелгән.

**6. «Өч баһадир» мультфильмыннан өзек**

Өч баһадир: Алёша Попович, Добрыня Никитич һәм Илья Муромец рус җире намусы өчен сакта торалар, рус анасын коткару хакына батырлык эшлиләр.

**5 нче тур – «Ситуациягә бәя бир»**

Командаларга чиратлап сорау бирелә. Һәр дөрес җавап 1 балл белән бәяләнә.

1. Регина апасына почта таратырга булыша.Ул дуслары, танышлары тормышы белән бик кызыксына, шуңа күрә кайвакыт башкаларга юлланган хатларны укый. Ул нинди хокук боза? *(Һәркемгә хат алышу, телефоннан сөйләшү сере гарантияләнә. Искәрмә законда каралган очракта гына булырга мөмкин.)*

2. Чүп түгәргә чыкканда балигъ булмаган баланы полиция тоткарлаган, тоткарлауның сәбәбен хәбәр итмәгән. Баланың нинди хокуклары бозылган? *(Ирек һәм шәхси хокук кагылгысызлыгы.)*

3. Белдерү: «Безнең мәктәпкә татар телендә сөйләшүче, әти-әниләре ислам дине тотучы балалар гына кабул ителә». *(Дин ирегенә хокук, белемгә хокук.)*

4. Полиция беркетмәсеннән: «Ике кеше (шаһитлар күрсәтмәләре буенча) 2023 елның 6 февралендә ишекне ватып, «Идел» массивындагы дача йортына үтеп керделәр. Йорт янына машина килү сәбәпле бернәрсә дә урларга өлгермәгәннәр һәм качарга мәҗбүр булганнар. *(Йортның кагылгысызлыгына хокук.)*

**Вердикт.** Карар чыгару өчен сүз хөкемдарларга бирелә.

**III. Йомгаклау.**

**Укытучы.** Укучылар, Россияне яратыгыз, аның киләчәге сезнең кулда, һәм ул сез ясаган кебек булыр. Мин ышанам, сез Россиянең чын гражданнары булырсыз.

**IV. Рефлексия**

**Укытучы.** Укучылар, үзегезнең чарадан алган тойгыларыгыз, фикерләрегез белән уртаклашсагыз иде. Моның өчен җөмләләрнең берсен төгәлләгез:

– Минем өчен шул яңалык булды: ...

– Мин шуны белдем: ...

– Минем өчен шул кызыклы булды: ...

# Яшь буынны гражданлык һәм ватанпәрвәрлек рухында тәрбияләүдә мәктәп музееның роле



**Илнур ГАЛИМОВ,**
*Балык Бистәсе районы
Яңа Арыш урта мәктәбенең
тарих һәм җәмгыять белеме
укытучысы*

Яңа федераль дәүләт белем бирү стандартлары рухи үсешнең төп шарты буларак яшь буынга ватанпәрвәрлек һәм гражданлык тәрбиясе бирүне куя.

Дөрес, моңа кадәр дә гражданлык һәм ватанпәрвәрлек хисе тәрбияләү белем бирүнең мөһим максатларының берсе булып торды. Чөнки дәүләт белән аның гражданнары арасында үзара җаваплылык мөнәсәбәтләре булмаган илнең киләчәге була алмый. Дәүләтебезгә куркыныч тудырган бүгенге вазгыять шартларында бу проблема аеруча актуаль булып алга килеп баса.

Билгеле инде ватанпәрвәрлек хисе үзеннән-үзе генә барлыкка килә алмый. Моның өчен күп факторларның туры килүе мөһим. Шәхеснең әйләнә-тирә мохите, гаилә тәрбиясе, коллективтагы мөнәсәбәтләр – боларның барысы да ватанпәрвәрлек тәрбиясендә үз ролен башкара. Ләкин укучыларга рухи-әхлакый тәрбия бирү, ватанпәрвәрлек, гражданлык хисләре уяту мәсьәләсендә мәктәп һәм укытучыны бернәрсә дә алыштыра алмый. Тарих, тормыш иминлеге нигезләре дәресләре, тематик тәрбия сәгатьләре – болар барысы да гражданлык, ватанпәрвәрлек тәрбиясе бирүдә үтемле чаралар. Ә инде бу дәресләр музей педагогикасы белән үрелеп барганда, аларның эффективлыгы тагын да арта. Музей тәрбия эшен күрсәтмәлелек белән баетып кына калмый, үткән буыннар тәҗрибәсен бүгенге чынбарлык белән тоташтыручы мөһим фактор булып тора.

Яшь буында Ватаныбызга, аның данлы үткәненә хөрмәт һәм мәхәббәт хисләре тәрбияләү хакында үзебезнең мәктәп музеебыз эшчәнлеге мисалында күрсәтеп китәсем килә. «Мәктәп музее» төшенчәсе иң беренче чиратта аның урыны түгел, ә үзенчәлеген белдерә. Музейның төп эш юнәлеше нәкъ менә укучыларга, аларны илебезнең чын гражданнары итеп тәрбияләүгә багышлана.

Безнең Яңа Арыш урта мәктәбе музее үзенең эшчәнлеген

